**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 25 » 10 2019 № 673

Аксубаево

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 30 октябрендәге 366 номерлы карары белән расланган «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеген раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «2016-2020 елларга халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү» муниципаль программасына (Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының 30.10.2015ел. №366 нчы карары) (алга таба-Программа), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

-программа атамасында «2016-2020» санын «2016-2022» санына алмаштырырга;

-программа паспортында: «программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | 2016-2022 еллар |

«программаны финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләме | 2016-2022 елларга Программаны финанслау күләме 9839,9 тәшкил итә. шул исәптән, мең сум:<br>2016 ел –1044,2 мең сум<br>2017 ел – 1257,2 мең сум<br>2018 ел –1316,9 мең сум<br>2019 ел-1474,3. мең сум<br>2020 ел-1523,3 мең сум<br>2021 ел- 1580,6 мең сум<br>2022 ел- 1643,4 мең сум<br>Искәрмә:программаны финанслау күләме алдан фаразланган характерга ия һәм тиешле дәрәҗәдәге бюджетларны формалаштыруны , шулай ук чараларны финанслашуга федераль һәм республика бюджетыннан акча бүлеп бирүне исәпкә алып, ел саен корректировкаланырга тиеш |

- «Программаны ресурс белән тәэмин итүне нигезләү» бүлегенең икенче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Программаны финанслауның гомуми күләме 9839,9 мең сум тәшкил итә. Программаны тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү фаразланган характерга ия һәм, район бюджеты акчалары мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен корректировкаланырга тиеш»;

- «программаны тормышка ашырудан социаль-икътисадый һәм экологик нәтиҗәләрнең нәтиҗәлелеген бәяләү» бүлегенең икенче абзацында «2016-2020» саннарын «2016-2022»гә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының интернет челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http: //aksubayevo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Александровка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе А. Ф. Горбунов